КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 23 гыйнвар г.Казань № 25

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының каникул вакытында балалар ялын оештыру буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының каникул вакытында балалар ялын оештыру буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 23 гыйнвар, 25 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының каникул вакытында балалар ялын оештыру буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртиптә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының каникул вакытында балалар ялын оештыру буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба шул ук эзлеклелектә – муниципаль берәмлекләр, субсидияләр) бирү кагыйдәләре билгеләнә.

2. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3. Субсидияләр муниципаль берәмлекләр бюджетларына әлеге Кагыйдәләрнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Субсидияләр түбәндәге критерийларга җавап бирүче муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан оештырыла торган балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча ведомствоара комиссия белән килештерелгән каникул вакытында балалар ялы буенча муниципаль программа булу; әлеге программада әлеге Тәртипнең 14 пунктында күрсәтелгән, Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына субсидияләр бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) нигезендә зурлыклары билгеләнә торган субсидияләрне куллану нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәләренең) максатчан күрсәткечләреннән гыйбарәт каникул вакытында балалар ялын оештыру буенча чаралар исемлеге күрсәтелә;

муниципаль берәмлекнең ведомство буйсынуындагы каникул вакытында балалар ялын оештыру буенча хезмәтләр күрсәтүче муниципаль оешмалары булу.

5. Муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында субсидияләрнең бүленеше тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында билгеләнә.

6. Субсидия бирү шартлары:

муниципаль берәмлекнең финанслашу максаты белән субсидия бирелә торган каникул вакытында балалар ялын оештыру чаралары исемлеген үз эченә алган каникул вакытында балалар ялы буенча муниципаль программаны раслау турында муниципаль хокукый акты булу;

килешү төзү.

7. Субсидия алу өчен муниципаль берәмлек Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидия бирүгә заявка;

әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән муниципаль берәмлекнең муниципаль хокукый акты күчермәсен;

муниципаль берәмлекнең ведомство буйсынуындагы каникул вакытында балалар ялын оештыру буенча хезмәтләр күрсәтүче муниципаль оешмалары исемлеген.

8. Муниципаль берәмлеккә субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

муниципаль берәмлек тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 7 пунктында каралган таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

муниципаль берәмлек тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнү.

9. Әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документлар (алга таба – документлар) Министрлык тарафыннан кергән көнне аларның керү вакытын һәм датасын күрсәтеп теркәүгә алына.

10. Документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Министрлык, алар кергән көннән 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидия бирү һәм килешү төзү турында яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

11. Субсидия, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 ел, 20 сентябрь, 851 нче карары белән расланган Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренең (алга таба – Субсидияләрне формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләре) 10 пунктына таянып, Министрлык һәм муниципаль берәмлек арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча төзелә торган килешү нигезендә бирелә.

12. Муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган субсидия күләме ($S_i$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_i = \left( \sum_{i=1}^{n} \sum_{j=1}^{m} N_{ij} \times P_{ij} \times NFZ_i \times Y_{si} + N_k \times NFZ_k \right) \times L_i,$$

монда:

$N_{ij}$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 158 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Балалар һәм яшьләр ялын оештыру» төбәк проекты (алга таба – төбәк проекты) нигезендә балалар ялын оештыру буенча муниципаль хезмәтләр күләме;

$P_{ij}$ – төбәк проекты нигезендә балалар һәм яшьләр ялы оешмаларында смена озынлыгы;

$NFZ_i$ – муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр күләмен исәпләгәндә кулланыла торган балалар ялын оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар. Муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр күләмен исәпләгәндә әлеге норматив чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең норматив чыгымнарына тигез итеп кабул ителә;

$Y_{si}$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауда өлешләп катнашу күләме;

$N_k$ – төбәк проекты нигезендә дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең, шулай ук муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан коммерциячел һәм коммерциягә карамаган оешмалар (муниципаль һәм дәүләт оешмаларыннан тыш) балалары арасыннан балалар ялын оештыру буенча муниципаль хезмәтләр күләме;

$NFZ_k$ – муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр күләмен исәпләгәндә кулланыла торган муниципаль оешмалар һәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең, шулай ук муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан коммерциячел һәм коммерциягә карамаган оешмалар (муниципаль һәм дәүләт оешмаларыннан тыш) хезмәткәрләренең балалары арасыннан балалар ялын оештыру буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүгә норматив чыгымнар. Муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр күләмен исәпләгәндә әлеге норматив чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган муниципаль оешмалар һәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең, шулай ук муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан коммерциячел һәм коммерциягә карамаган оешмалар (муниципаль һәм дәүләт оешмаларыннан тыш) хезмәткәрләренең балалары арасыннан балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүне тәэмин итүнең норматив чыгымнарына тигез итеп кабул ителә;

$L_i$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан ел саен раслана һәм Субсидияләрне формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 13 пункты нигезендә билгеләнә торган Татарстан Республикасы бюджетыннан i муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен финанслашуның иң чик дәрәҗәсе;

i – балалар һәм яшьләр ялын оештыру формасының тәртип саны;

j – балалар һәм яшьләр ялы чорының тәртип саны;

n – балалар һәм яшьләр ялын оештыру формалары саны;

m – балалар һәм яшьләр ялы чорлары саны.

13. Субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү әлеге Тәртипнең 14 пунктында күрсәтелгән субсидиядән файдалану нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәләренең) максатчан күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

14. Субсидиядән файдалану нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәләренең) максатчан күрсәткечләре:

а) ял төрләре буенча оештырылган ял формаларына балалар җәлеп итү (процент), шул исәптән:

палатка тибындагы лагерьда профильле сменаларда;

мәгариф оешмалары тарафыннан ел дәвамында каникул чорында оештырылган көндезге лагерьлардагы сменаларда;

Татарстан Республикасы карамагындагы дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең балалары өчен шәһәр яны стационар лагерендагы сменаларда;

коммерциячел һәм коммерциягә карамаган оешмалар хезмәткәрләренең балалары өчен шәһәр яны стационар лагерындагы сменаларда;

шәһәр яны лагерындагы юнәлешле сменада;

хезмәт һәм ял лагерендагы сменада;

б) савыктыру эффектын арттыру (процент).

15. Субсидияләр тиешле финанс елына кадәрге елның 15 декабренә кадәр Министрлыкка җибәрелә торган документлар нигезендә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләменнән һәр кварталга түбәндәгечә бүленеп бирелә:

I квартал (5 февральгә кадәр) – 25 процент;

II квартал (5 апрельгә кадәр) – 45 процент;

III квартал (5 июльгә кадәр) – 15 процент;

IV квартал (5 ноябрьгә кадәр) – 15 процент.

16. Министрлык килешү төзелгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә субсидия акчасын килешү нгезендә муниципаль берәмлекләрнең финанс органы тарафыннан Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсендә ачылган муниципаль берәмлекләр бюджетларының бердәм счетларына күчерә.

17. Муниципаль берәмлекләр Министрлыкка килешүдә каралган формада, срокларда һәм тәртиптә финанслашу максатларында субсидия бирелә торган җирле бюджет чыгымнарын гамәлгә ашыру турында, шулай ук субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре зурлыкларына ирешү турында хисаплар тапшыра.

18. Муниципаль берәмлекләр бирелә торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм субсидияләрнең максатчан файдаланылмавы өчен законнар нигезендә җавап бирә.

19. Килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган очракта, муниципаль берәмлекләр бюджетларыннан Татарстан Республикасы бюджетына акчаны кире кайтару тәртибе һәм шартлары Субсидияләрне формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 15 – 20, 23 пунктларында билгеләнде.

20. Муниципаль берәмлек тарафыннан субсидия максатчан файдаланылмаган һәм (яки) аны бирү шартларын бозылган, шул исәптән әлеге Кагыйдәләрнең 15, 19 һәм 20 нче пунктлары нигезендә акча муниципаль берәмлек тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата

Россия Федерациясе бюджет законнары белән күздә тотылган мәҗбүр итүнең бюджет чаралары кулланыла.

21. Субсидияләрне бирү һәм (яисә) максатчан файдалану шартлары үтәлешен контрольдә тоту Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

22. Агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата субсидиянең файдаланылмый калган өлеше, Килешүдә каралган очракларда, агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидиянең файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемenә күчерелмәгән очракта, әлеге акча Татарстан Республикасы бюджеты керемenә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләтелергә тиеш.